وَاعْتَصِمُوا بِحَبْلِ اللَّهِ جَمِيعًا وَلَا تَفَرَّقُوا

Ий мөэминнәр! Барчаларыгыз да берләшкән хәлегездә Аллаh арканына, ягъни Аның диненә ныклап ябышыгыз! Һәм һич тә аерылмагыз һәм бер-берегездән киселеп, төрле юлларга китмәгез!

6+

# Дин вә Мәгыйшәт

№26 (169). 28 декабрь 2012 / 15-сәфәр-1434

ТАТАРСТАН МӨСЕЛМАННАРЫ ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕ БАСМАСЫ



ИСЛАМ САЙТЛАРЫ АССОЦИАЦИЯСЕ: АЛЛАҺНЫҢ РИЗАЛЫГЫН АЛУ ӨЧЕН КАЛӘМГӘ ТОТЫН! ▷2◁



МӘҢГЕ СҮНМӘС ӨМЕТ ▷3-4◁



ГАБДУЛЛА ТУКАЙ ИҖАТЫ ҺӘМ ИЛАҺИЯТ КАНУННАРЫ ▷3-4◁

## Җаваплылык - ислам динендә иң төп төшенчәләрнең берсе

**"Күкләргә, Җиргә вә таууларга Без әманәт тәкъдим иттек, ләкин алар (җаваплылыктан куркып) бу йөкне үз өсләренә алмады. Адәм баласы бу әманәтне үз өстенә алды. Чөнки кеше - (табигате белән) залим һәм надандыр" ("Әхзаб (Төркем)" сүрәсенең 72 нче аяте).**



Җаваплылык - ислам динендә иң төп төшенчәләрнең берсе. Ислам дине хакыйкатен танып та, без үз өстебезгә зур җаваплылык алуыбызны инкяр итә алмыйбыз. Без, барыннан да элек, Аллаhы Тәгалә каршында җаннарыбыз өчен җаваплы. Без үзебезгә җибәрелгән барлык сынауларны җаннарыбызны каралтмыйча, Аллаhы Тәгалә алдында чиста калып, җиңеп чыга алуыбызны беләбез. Үзебездән тыш, без башкалар өчен дә җаваплы. Һәр ике җаваплылыкны бер-берсеннән аеру кыен, чөнки кешелек дөньясы бербөтен организм кебек. Рәсүлебез Мөхәммәд (сгв) әйтүенчә, тәннең бер әгъзасы авыртса - бөтен организм авырый дигән сүз. Без бу хакыйкатьне еш кына онытабыз һәм үзләрен генә яратучы эгоистларга әйләнә башладык. Безне башка кешеләрнең ихтыяҗлары борчымый икән, бу үз өстебезгә алган җаваплылык турында онытуыбызны күрсәтә.

Әйдәгез, бай булмаган, башкаларга матди ярдәм күрсәтә алмаган гади бер кешенең башка кеше тормышын үзгәртә, аны коткарып кала алуын карыйк. Аклыкматурлык белән бергә хәвеф-хәтәрләр дә алып килүче кыш җитте. Юлларда торак-коммуналь хуҗалыгы хезмәткәрләре чистартырга җитешмәгән бозлавыклар, кар өемнәре, йорт түбәләрендә боз сөңгеләре барлыкка килде.

Үзегезне генә кайгыртмагыз, тукталышта юл аша чыгарга куркып торган әбигә, боз сөңгесе астында уйнаган балачагага яки күршегез куйган машинага игътибар итегез. Мондый игътибар вак-төяк нәрсә кебек кабул ителә, ләкин безнең тормышыбыз менә шундый вак-төякләрдән тормыймыни?! Башкаларга игътибарлы булган очракта бәхетсезлекне булдырмый калу - үз кулыбызда. Революцияләр оештырып кына Аллаhы Тәгаләнең рәхмәтенә ирешеп була димени?! Әгәр дә кеше эшкә барганда аннан тизрәк кайту турында гына түгел, ә күпләрнең язмышы аңа да бәйле икәнне уйласа, ул үз эшенә дә, тормышына да җаваплырак булыр иде.

Пәйгамбәребез (сгв) болай дигән: "Сез барыгыз да көтүчеләр һәм сез барыгыз да үзегезнең көтүегез өчен җаваплы (кемнәр өчен җавап бирергә тиешсез, шулар өчен җаваплы)".

Җәмгыятькә файда китерә торган теләсә нинди гамәл Аллаhы Тәгаләгә сыену һәм Адәм галәйһиссәлам үз өстенә алган җаваплылыкны үтәү ул.

***Үзәкләшкән дини оешма - Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте рәисе, мөфти Илдус хәзрәт ФӘИЗ***

## БИШ НӘРСӘНЕ ДӨРЕС КУЛЛАН!

**Аллаhы Тәгалә Коръәни-Кәримдә әйтә: "Әйт, йә Мөхәммәд, Аллаhы Тәгалә камил кодрәте белән сезне яраткан, ишетүче колак, күрүче күз, йөрәк биргән Зат. Сез хак сүзләрне ишетсен, кодрәт дәлилләрен күрсен һәм шуларны фикерләсен өчен".**



Әйе, җәмәгать, Аллаhы Тәгаләнең биргән нигъмәтләре күп:

Аллаhы Тәгалә безгә ошбу тормышны, җирдә яшәүне насыйп әйләде.

Аллаhы Тәгалә безгә яшьлекне, картлыкны бирде.

Аллаhы Тәгалә безгә дөрес файдалану өчен вакытны бирде.

Аллаhы Тәгалә безгә шөкер итүебез өчен сәламәтлек, авыру-чирләр бирде.

Аллаhы Тәгалә безгә сынау вә фикерләү өчен байлыкны вә ярлылыкны бирде.

Аллаhы Тәгалә безгә ошбу дөньяда хезмәт кылу, аңардан гыйбрәт алу һәм дөньяга ни өчен килүебезнең максатын аңлап, мәңгелек Ахирәткә әзерләнү өчен акыл бирде.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд (сгв) әйткән: "Биш нәрсәне дөрес куллан, киләчәк бишесенә җиткәнче:

1. Яшьлегеңне - картлык килгәнче.

2. Сәламәтлегеңне - чир килгәнче.

3. Байлыгыңны - ярлылык килгәнче.

4. Буш вакытны - мәшгульлек килгәнче.

5. Тормыш вә яшәвеңне - үлем килгәнче".

Пәйгамбәребез (сгв) безгә шул рәвешле Аллаh биргән нигъмәтләрне вакытында һәм дөрес куллануның әһәмиятен аңлатып биргән. Аларга киңрәк тукталып китик.

1. Яшьлегеңне файдаланып кал (картлык килгәнче). Чөнки яшьлек ул көчле, гайрәтле вакыт. Аны дөрес файдаланганда кеше Аллаhы Тәгалә каршында бөек дәрәҗәләргә ирешә. Яки Кыямәт көнендә Гареш күләгәсенә лаек булган хәерле җиде төркем кешеләр арасына керә. Бу көнне Гареш күләгәсеннән башка бернинди сыену урыны булмаячак. Кызулыктан кешеләр үз тирләреннән тончыга башлаган бер вакытта Аллаhы Тәгалә җиде төркемне Үз яклавы астына алачак һәм шулар арасында Аллаhы Тәгаләгә гыйбадәт кылып үскән яшь кеше дә булачак.

Безнең көннәрдә яшәүче галимнәрнең берсе язган: "Хәзерге вакытта мөмкин бөек кеше булырга, байлыкка ирешергә, элеккеге гаскәр башлыклары, дөньяны яулаучылар дәрәҗәсенә менәргә. Әмма минлекне узу, үз нәфес-теләкләреңә каршы тору бик авыр". Пәйгамбәребезнең (сгв): "Иң зур җиһад - үзеңнең нәфсең белән көрәшү", - дигән сүзләре әнә шулай бүгенге көн өчен дә бик мөһим. Хәтта үткән чорга караганда да мөһимрәк: безгә әле сәхабәләр дәрәҗәсенә җитү бик авыр. Алар - үз нәфселәренең колы булмаган кешеләр. Мәшһүр гаскәр башлыгы Халид ибн әл-Вәлид (үз

*(Ахыры 2 нче биттә.)*

## ЯҢАЛЫКЛАР

**ОЧРАШУ УЗДЫ**

**20 декабрь көнне Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең ярдәм күрсәтү һәм хәйрия бүлеге хезмәткәрләре Түбән Кама мөхтәсибәтендә булды.** Алар "Балкыш" яшүсмерләр социаль-тернәкләндерү үзәген һәм Балалар йортын карады. Шулай ук мөфтиятнең бүлек мөдире Гөлнара Садыйкова Түбән Кама Җәмигъ мәчете хатын-кызлары оешмасы утырышында катнашып, Диния нәзарәте тарафыннан алып барыла торган хәйрия эшчәнлеге турында сөйләде.

Утырышта район имам-мөхтәсибе Йосыф хәзрәт Дәүләтшин да чыгыш ясады. Очрашу ахырында мәчет эшчәнлегенә кагылышлы фильм күрсәтелде.

**МӨСЕЛМАН ЯШЬЛӘРЕ ЯРЫШЛАРДА КӨЧ СЫНАШТЫ**

**4-19 декабрь көннәрендә Казан шәһәренең мөселман яшьләре арасында Спартакиада ярышлары узды.**

Чараны Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте һәм Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты оештырды.

Ярышлар җиңел атлетика, стритбол, футбол, өстәл теннисы буенча үтте.

Башкалабызның мөселман яшьләре арасында узган IV Спартакиадада Россия ислам университеты командасы җиңүче дип табылды. II урынга "Мөхәммәдия" мәдрәсәсе командасы лаек булды. III урынны Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге мәдрәсә шәкертләре яулады.

Җиңүче команда күчмә кубок һәм беренче дәрәҗәдәге диплом белән бүләкләнде.

**РОССИЯДӘ "МӨСЕЛМАННАРНЫҢ ГАЕПСЕЗЛЕГЕ" ФИЛЬМЫ РӘСМИ РӘВЕШТӘ ТЫЕЛДЫ**

**РФ Юстиция министрлыгы "Мөселманнарның гаепсезлеге" фильмын рәсми рәвештә Россиядә тыелган фильмнар реестрына кертте.**

Материал тыелганнар исемлегенә Мәскәүнең Тверь район суды карары чыкканнан соң кертелде.

Прокуратура сорап алган психологик-лингвистик тикшеренү фильмның эчтәлеге дини дошманлык уятуга, шулай ук дине һәм дингә мөнәсәбәте буенча кешене кимсетүгә юнәлдерелгән булуын раслады.

Исегезгә төшерәбез: 1 октябрь көнне Мәскәү шәһәренең Тверь район суды материалны экстремистик дип таныды һәм ил буенча таратуны тыю хакында карар чыгарды. Әмма ноябрь аенда документларның идарәгә килеп җитмәве сәбәпле, фильм тыелганнар реестрына кертелми торды дип хәбәр ителде. **WWW.ISLAM-TODAY.RU.**

***Мәгълүматлар ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең рәсми сайтыннан (www.dumrt.ru) алынды***

# БИШ НӘРСӘНЕ ДӨРЕС КУЛЛАН!

*(Ахыры. Башы 1 нче биттә.)*

вакытында ул римлыларны һәм фарсыларны буйсындырган) үзеннән соң бары тик сугыш киемнәрен, кылыч вә атын гына калдырган. Калган малын дин юлына тоткан. Үзенең соңгы көннәрендә ул кычкырып елаган. "Нигә елыйсың?" - дигән сорауга: "Мин бик күп сугышларда катнаштым. Тәнемдә кылыч, ук, сөңге эзе булмаган урын юк. Ә хәзер мин үлем түшәгендә бер файдасыз дөя шикелле", - дигән. Әйе, картлык килгәч, көч-куәт беткәч, әллә нәрсәләр эшлисең килсә дә, эшли алмассың. Шул вакытта яшь, көчле, әмма бушка үткән вакытың искә төшәр.

Һәр яктан төрле бозыклыклар ымсындырып торган бүгенге дөньяда яшьләргә, бигрәк тә кызларга мөслимә булып, Исламның бөтен шартларын үтәп яшәве авыр. Бу - бик зур сабырлык, тәкъвалык сорый.

2. Сәламәт чакта эшләп кал (чир килгәнче). Бүген без саусәламәт икән, онытмыйк: бу да Аллаһы Тәгаләнең безгә биргән бер нигъмәте, рәхмәте. Шуңа күрә сәламәтлегебезне Аллаһ ризалыгын ала торган хәерле эшләргә сарыф итик. Бүгенге көндә күпме кешене авыр чирләр баскан. Алар яшь, куәтле чакларында эшләмичә калган эшләре өчен үкенә. Пәйгамбәребез (сгв) әйткән: "Кыямәт көнне ошбу дүрт әйбер соралмыйча, Аллаһ колының аяклары хәрәкәткә килмәс: тормышыңны нәрсәгә сарыф иттең, тәнеңне ничек файдаландың, байлыгыңны ничек тупладың һәм аны кайларга тоттың, алган гыйлемнәреңне нәрсәгә юнәлттең".

Пәйгамбәребез (сгв) Аллаһы Тәгалә кушканча яшәргә өйрәтте, авыруларга каршы көрәш юлларын күрсәтте, дөрес тукланугa зур игътибар бирде. Хәдисләрнең берсендә болай диелә: "Барлык авыруларга дәва бар, тик картлыкка гына юк".

3. Булган байлыгыңны дөрес куллан (ярлылык килгәнче). Әгәр дә безнең байлыгыбыз, мөмкинлегебез, дәрәҗәбез җитәрлек икән, ул байлыкны, мөлкәтне, мөмкинлекләрне Ахирәт өчен эшләтергә ашыгырга кирәк. Дөньяда вакытта күпләр акчасын банкка сала, аны арттырырга тели, риба малына кызыгып гөнаһ эшли. Ә ни өчен соң аны Мәңгелек банк счётына салмаска? Андагы счётка риба да, кимү дә, кризис та, инфляция дә янамый. Хәерле эшләрнең әҗер-саваплары анда кирәк вакытка кадәр сакланачак. Ә дөньялыкта файдасызга туздырылган акча-байлыклар Ахирәттә зарар гына китерәчәк. Ә бит бүгенге мөмкинлекләребез, байлыгыбыз, дәрәҗәбез иртәгә булмаска да мөмкин. Шуңа күрә эш үткәннән соң үкенечкә калмасын.

4. Буш вакытыңны дөрес тот (мәшгульлек килгәнче). Пәйгамбәребез (сгв) әйткән: "Кешеләр Аллаһы Тәгалә биргән ике нигъмәтне дөрес бәяләмиләр һәм алданалар. Болар - сәламәтлек һәм буш вакыт". Күпләребез, Аллаһы Тәгалә алдындагы бурычларын онытып, 24 сәгатьне дә дөнья өчен кулланырга тырыша.

5. Тормышта дөрес яшә (үлем килгәнче). Тормыштагы иң зур хатабыз - дөньяга нигә яратылганыбызның максатын аңламау, сыналу өчен генә килгәнебез хакында фикер йөртмәү. Аллаһы Тәгалә безгә ошбу яшәешне Ахирәткә әзерләнү өчен бирде. Ягъни дөнья-ахирәт эшләрен бергә алып бару кирәк. Ислам - безнең яшәү рәвеше дә, Ахирәт бәхетенә ирешү рәвеше дә. Шуңа күрә безнең барча эшләребез - фикерләвебез дә, киенүебез дә, үз-үзебезне тотышыбыз да шәригатьчә булырга тиеш.

**Әлфәс хәзрәт ГАЙФУЛЛА,**
**Татарстан мөселманнары**
**Диния нәзарәтенең**
**Президиум әгъзасы,**
**Чаллы шәһәре**
**имам-мөхтәсибе**

# ИСЛАМ САЙТЛАРЫ АССОЦИАЦИЯСЕ:
## АЛЛАҺНЫҢ РИЗАЛЫГЫН АЛУ ӨЧЕН КАЛӘМГӘ ТОТЫН!

**21 декабрь көнне Татарстан мөфтиятендә "Ислам интернеты: эшлекле сөйләшү" дип аталган "түгәрәк өстәл" узды. Башкалабызга илебезнең әйдәп баручы мөселман интернет-сайтлары вәкилләреннән эчкерсез һәм нәтиҗәле эшләр башкарырга әзер торучы егетләр җыелды. Алар бердәмлек, мәгълүматны бердәм идеологик юнәлештә алып бару, гомуми мәгълүмати сәясәт, мөселман журналистларының оперативлыгы һәм һөнәри осталыгы турында фикер алышты. Нәтиҗәдә, шушы максатларга ирешү өчен Ислам сайтлары ассоциациясе төзү турында килешенде.**



Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте рәисенең беренче урынбасары Габдулла хәзрәт Әдһәмов мондый сөйләшү һәм очрашуларны "online" тәртибендә оештырырга тәкъдим итте. Ул интернетны чүп чиләге белән дә чагыштырды. "Интернеттан дөрес файдалану кешелек җәмгыятенең үсешенә ярдәм итәчәк", - дип тә искәртте. "Ә шулай да әлеге могҗиза адәм баласына Аллаһы Тәгалә тарафыннан бүләк ителгән, әмма ни кызганыч, аны бөтен кеше дә игелек кылу өчен кулланмый шул", - дип ассызыклады ул. Җыенда катнашучыларга мөрәҗәгать итеп, Габдулла хәзрәт мөселман гаммәви матбугат чаралары җитәкчеләрен укучыларга ислам дине турында хакыйкый мәгълүмат таратырга, аның тәрәккыяткә өндәүче рухи-әхлакый кыйммәтләрен калкурак күрсәтергә чакырды. Моңа мисал итеп: "Пычак ярдәмендә җинаять кылырга да, ифтарга җыелган мохтаҗларга ризык әзерләп ашатырга да мөмкин", - диде хәзрәт.

### "ӘҺЛЕ-СӨННӘТ ВӘЛ-ҖӘМӘГАТЬ БЕРДӘМ БУЛЫРГА ТИЕШ"

"Түгәрәк өстәл"дә катнашучыларны борчыган проблемалар бер-берсенә бик тә якын. Ислам турында язучы журналистлар алдында торган җитди мәсьәләләрнең чишелешен беренчеләрдән булып Islam-today.ru сайты вәкиле Марсель Сабиров ачты. Иң әүвәл, ул мөселман мәгълүмат чаралары өчен кадрлар әзерләү проблемасына тукталып үтте. Аның сүзләренә караганда, журналистларның тәҗрибәсе булмаганлыктан, материалларның сыйфаты түбән була һәм оперативлык та югала икән.

"Мин аналитик мәкаләләр язу өчен сәясәт белгечләрен, икътисадчыларны җәлеп итү ягында, чөнки Ислам сайтларындагы мәкаләләрнең эчтәлеге бик сай, аларда аналитик фикер күренми. Мөселман басмаларының зур өлеше дәгъват мәсьәләләренә карый. Монда барлык Ислам сайтларына да чама белән бердәм мәгълүмати нигезгә таянырга кирәк дип саныйм һәм бу хакта безгә тиешле килешү дә кабул итү мәслихәт. "Әһле-Сөннәт вәл-Җәмәгатьнең бердәм җитди блок булып хәрәкәт итүе зарур, - дип ассызыклады М.Сабиров. - Яңалыкларны без төрле яктан якын килеп яктыртсак та, динихокукый нигезебез бердәм булырга тиеш".

Россиядә сиксәнләп мөфтият бар, әмма шуларның яртысының интернет челтәрендә сайтлары юк. М.Сабиров фикеренчә, гамәлдәге сайтларга көненә берәр хәбәр урнаштырылып килсә дә, Ислам темасына яза торган журналистларның эше шактый җиңеләер һәм иң мөһиме - башка төбәкләрдә яшәүче мөселманнар тормышы турында күбрәк белеп бару мөмкинлегe туар иде.

### "БЕЗ ИСЛАМ БЕЛӘН БӘЙЛЕ БУЛМАГАН МАТБУГАТ ЧАРАЛАРЫНДА ЭШЛӘҮЧЕ ЖУРНАЛИСТЛАРГА ЯРДӘМ КУЛЫ СУЗАРГА ТИЕШ"

"IslamNews" мәгълүмат агентлыгы вәкиле Алмаз Габдрахманов үзенең чыгышында интернетны гаммәви мәгълүмат чарасы буларак куллануның мөселманнар өчен сөннәт гамәл булуын искәртте. Чөнки Пәйгамбәребез (сгв) үзе яшәгән чордагы матбугат чараларын куллланудан тайчанмаган.

Алмаз фикеренчә, бүгенге көндә иң мөһим максатларның берсе - мөселман гаммәви мәгълүмат чараларын берләштерү һәм аларны эшлекле хезмәттәшлеккә юнәлдерү. Мәгърифәтчелек юнәлешендә эшне көйләү өчен дә тыгыз элемтәдә тору әһәмиятле, дип саный А.Габдрахманов.

"Дингә турыдан-туры бәйле булмаган мәгълүмат чараларында хезмәт куючы каләмдәшләребезгә ярдәм кулы сузарга тиешбез. Рейтинг артыннан куып, матбугат чаралары мәгълүматны еш кына төрлечә үзгәртеп язу юлына баса. Без вакыйгаларның асылын аңлатмаган очракта, Исламга бәйле булмаган матбугат органнары аларны үзгәртеп игълан итә. Шунлыктан, хәбәрләрнең эчтәлеге үзгәрә яки ул укучыларга аңлашылмый торганга әйләнә. Бар көчебезне бер ноктага туплаган очракта гына максатларыбызга ирешә алырбыз".

А.Габдрахманов фикеренчә, көнүзәк мәсьәләләрне чишү бердәм рәвештә барырга тиеш. Бу аеруча соңгы вакытта - экстремистик фикерләр көчәйгәндә, яшьләр арасында әллә нинди уйдырмалы карашлар тамыр җәйгән чакта бик тә әһәмиятле.

### "САЙТНЫҢ УҢЫШЫ ЭЧКЕРСЕЗЛЕККӘ БӘЙЛЕ"

Бу хакта Islamdag.ru һәм Islam.ru сәхифәләреннән килгән Хаҗи-Морат Рәҗәпов әйтте.

"Биредә интернетның асылын аңлаучы кешеләр җыелган, - дип искәртте ул. - Шуңа да, минем уйлавымча, теләсә нинди интернет сәхифәсенең, китапның яки мәкаләнең уңышы - аның ихлас күңелдән язылган булуында. Адәм баласы, каләм алып, Аллаһ ризалыгына ирешергә тели икән, аның мәгълүматы кешеләрнең күңеленә үтеп керәчәк. Нәтиҗәдә, ул хәбәрне укып, бер генә кеше булса да хакыйкать юлына басса, бәрәкәт иңәчәк".

### "МӨСЕЛМАН ЖУРНАЛИСТИКАСЫ ЮК УЛ"

Данис Гәрәев фикеренчә, мөселман журналистикасы, Ислам гаммәви матбугат чаралары дигән төшенчәләр чынлыкта юк. Бары тик "яхшы итеп хәбәр бирә белүче" һәм "булдыксыз хәбәрче", "яхшы аналитик" һәм "булдыксыз аналитик", "яхшы журналист" һәм "булдыксыз журналист" дигән төшенчәләр генә яшәп килә.

"Мөселман журналистикасы дигән жанр, гомумән, буш сүз ул, - дип белдерде Данис. - Биредә сүз һөнәри осталык турында бара. Интернетта мөселман сегментына күз салсак, гаммәви мәгълүмат чаралары белән генә чикләнмәскә иде, чөнки биредә киңрәк мәгънәдәге "медиа" төшенчәсе булуын да истән чыгармаска кирәк. Анда исә матбугаттан тыш, "социаль челтәр", "блог" та бар".

Мәгълүматны кабул итүчеләрнең еш кына информацион процесста катнашучыларга әверелүен дә искәртеп узды Д.Гәрәев. Элек журналистлар һәм укучылар гына булган булса, хәзер укучылар профессионал журналистлар һәм мөхәррирләр белән бертигез дәрәҗәдә көнүзәк проблемаларны чишүдә дә катнаша ала. Хәзер көн тәртибе блогерлар, аккаунттан файдаланучылар тарафыннан калыплаша. Еш кына алар телевидение, радио өчен мөһим булган темаларны казып чыгара. Моңа мисал итеп, Д.Гәрәев кайбер мөһим темаларның социаль челтәрдә "куерып", шуннан соң гына гадәти матбугат чараларында күтәрелүен искә төшерде.

Бүгенге көндә без мөселман кешесе халык арасында ялгышлык эшләсә, аны шундук челтәргә элеп куярлар да, өммәтебезгә шуның "күләгәсе төшәчәгенә" шаһит булып торабыз.

**(Ахыры 4 нче биттә.)**

# МӘҢГЕ СҮНМӘС ӨМЕТ

## Аягыңны чабатаң кысса

Һәрбер кеше бәхеткә омтыла. Адәм балалары бер-берсеннән яше һәм җенесе, милләте һәм акылы, зәвыгы һәм мәсләге, нияте һәм дөньяга карашы белән аерылырга мөмкин, ләкин бер максат барлык кешеләр өчен уртак булып тора. Ул да булса - бәхет эзләү: законнарга итагать кылучы һәм җинаятьче, Аллаһка ышанучы һәм кяфер - боларның һәммәсе дә бәхетле булырга тели. Ләкин нәрсә соң ул бәхет? Бу төшенчәнең асыл мәгънәсе нидән гыйбарәт соң? Моны аңлау бик тә мөһим, чөнки күпләр бәхеткә илтүче юлны сайлаганда ялгыша һәм ахыр чиктә бәхетсезлеккә юлыга. Бу мәсьәлә хакында уйлану һәр чорга, һәр милләткә, һәр кешегә хастыр. Безнең әби-бабаларыбыз да: "Бәхет бит ул гөлләр түгел, сулар сибеп үстерергә..." - дип юкка гына җырламаганнардыр.

Бүгенге җәмгыять кешеләренә килгәндә, алар еш кына күршеләренә, хезмәттәшләренә, "хәлле" танышларына игътибар итәләр һәм тышкы тәэсирләргә генә нигезләнеп уйлыйлар: "Ни өчен мин дә болай яшәмим соң? Әгәр мин дә шулай яшәгән булсам, һичшиксез, бәхетле булыр идем…"

Чынбарлыкта исә, әгәр тышкы яктан бәхетле булып күренгән кешеләрдән: "Сез тормышыгыздан канәгатьме?" - дип сорасаң, күп очракта алар тискәре җавап бирәчәкләр. Дөрестән дә, кайберәүләр бай, ләкин авыру (кайчакта зур акчага алынган дарулар һәм кыйммәтле курортлар да булышмый). Әгәр кемдер бай да, сау-сәламәт тә ди, бу әле барыбер ул бәхетле дигән сүз түгел, чөнки аның хатыны (ире) яки балалары бозыклык, фәхешлек юлында йөрергә, ә эш урынында нindидер җитди күңелсезлекләр булырга мөмкин. Мәшһүр шагыйребез Габдулла Тукай да әйткән бит:

"Дөнья киңлегендә ни шатлык бар,
Аягыңны чабатаң кысса".

Аңлашыла ки, биредә "чабата" сүзен туры мәгънәдә генә түгел, киная рәвешендә дә аңлатып була: "чабата кысуы" - ул, мәсәлән, өйдә, гаиләдә тынычлык-татулык булмау, эш яки уку урынындагы проблемалар һ. б.

Шулай булгач, кайда икән соң ул бәхет чыганагы? Кайларда яшерелгән ул һәммәбезгә дә кирәк булган бәхет? Ошбу сорау-мәсьәлә буенча мин шактый күп таныш-белешләрем белән сөйләштем, төрле-төрле фикерләрне тыңладым, ләкин күңелемә хуш килердәй тулы җавапны гап-гади татар авылында, гап-гади бер карчыктан ишеттем.

## Әбекәй нәсихәте

Мамадыш районында минем бабамның бертуган апасы яши. Олы яшьтә булуына карамастан, Нурания әби әле дә аяк өстендә, әкрен генә булса да йөри, чәйләр әзерли, саташмыйча иплəп кенә сөйләшә һәм бик еш тирән мәгънәгә ия хикмәтле фикерләр әйтеп куя. Кайчакта, шушы 92 яшьлек карчыкта шундый зиһен һәм фәлсәфи мантыйк ничек сакланган икән дип хәйран каласың. Әйтергә кирәк, Нурания әби шактый авыр һәм михнәтле гомер кичергән: сугыш, ачлык, авырулар, көчтән килмәслек эш, иң якын туганнарны югалту... Шулай да әбекәй диннән аерылмаган, намазларын калдырмаган.

Бәхет турында уйланып йөри башлагач, мин Мамадыштагы әбинең дә фикерен белергә теләдем һәм җай туры килеп, аның белән гәпләшеп алдым.

- Нурания апай, син ничек уйлыйсың, нәрсә ул бәхет?

- Бәхетме? Кемгә ничек инде ул, - дип ерактан башлады абыстай. - Һәркемнең үз карашы, үз аңлавы. Менә минем оныгым: "Машина сатып ала алсам - бик бәхетле булыр идем", - ди, килен исә телевизордагы киноларын вакытында караса, зур бәхеткә ия булгандай "очып" йөри. Ә мин алар яшендә тормыш иптәшем Хәбибулланы сугышка озаттым һәм соңыннан көн саен: "Йә Раббым, хәләл җефетемне ярты сәгатькә генә булса да кайтарсаң иде, бик күрәсем килә", - дип ялвардым. Сорый торгач, кабул булды бит догам: ирем каядыр үтеп барышлый 20 минутка гына йортыбызга сугылып чыга алды. Шуннан соң кайтмады, бер елдан һәлак булуы турында хәбәр килде. Ләкин шуның кадәр яраттым Хәбибулламны - шул 20 минутка кереп күрешеп китүе, аның сагыш тулы күзләренә карау минем өчен аңлатып бетерә алмаслык зур бәхет булды.

Бераз уйланып дәшми торганнан соң, әби сүзен дәвам итә:

- Моны инде гыйбрәт дип, мисал өчен генә сөйлим, чөнки кешенең күбесе бәхет туклык-муллык һәм иминлек булган җирдә генә йөри дип уйлый бит, улым. И-и, чынлыкта алай булсамы...

- Шулай да, толлык, ачлык һәм юклыкны бәхет галәмәтләре дип атап булмый бит инде, әби.

- Анысы да хак, әмма хикмәт мөнбәреннән караганда, муллыкта да бәхетсезләр юк дисеңме әллә? Кайгыны, күңелсезлекне акыл-сабырлык белән тиешенчә кабул итә алсаң, Аллаһ билгеләгән тәкъдиреңә буйсынучанлык күрсәтсәң, бәхетсезлек хисе үзеннән-үзе кими, басыла ул. Аллаһы Тәгалә биргән сынауны үти алсаң, бу олы дәрәҗә инде, улым. Дөньяда ул сынау - хәсрәт, авырлык, ләкин ахирәт мәгънәсендә - бәхеткә бер адым ясау мөмкинлеге. Тагын шуны исеңнән чыгарма: Аллаһны, ахирәтне онытып, бу дөньяга һәм кешеләргә генә өметләнә башласаң, тормыш авырлыкларын җиңүләр ай-һай... Фани дөнья өметләре - сабын куыгы кебек инде ул...

*(Ахыры 4 нче биттә.)*

# Габдулла Тукай иҗаты һәм илаһият кануннары

### Татар халкының иҗтимагый һәм рухи тормышын энциклопедистларча гәүдәләндерүче шагыйрь Габдулла Тукайның тууына быел 126 ел булды

**Ул - татар дөньясы чикләрен үтеп, халыкара хәзинәгә әверелгән, шигырьләре дөнья халыклары телләренә иң күп тәрҗемә ителгән шагыйрьләрнең берсе.**

XX йөз башы - татар әдәбияты тарихының Шәрык һәм Гареб традицияләре кисешкән, бергә аралашкан һәм синтез халәтенә кергән дәвере яңарышының күренекле вәкиле булган Габдулла Тукай шул җирлектә ярала, тамырлана һәм үсә. Шуңа күрә шагыйрь, Яңарыш вәкилләренә хас булганча, күңелендә иман саклый - әт-Тәүхид инанышына тугры кала һәм шул ук вакытта ул кешенең хөр, үз язмышына үзе хуҗа икәнлеген дә, диннең милли тәрәккыяткә, кеше бәхетенә хезмәт итәргә тиешлеге турында да авыз тутырып сөйли. Яңарыш вәкилләре һәм динне татар халкының тарихи-иҗтимагый барышына яраклаштырырга омтылучы дини реформаторлар кебек, Тукайның дингә мөнәсәбәтендә дә ике яклылык - бер яктан Алланы тану, динне халыкка хезмәт иттерергә омтылу, икенче яктан, тәрәккыят белән каршылыкка кергән дини тәртипләргә каршы чыгып, яңарышка омтылу күзәтелә.

Тукай иҗатында Коръән тәгълиматы, ислам фәлсәфәсе, Шәрык классик поэзиясе традицияләре, Көнбатыш Европа һәм рус әдәбиятларыннан үтеп кергән әдәби-эстетик фикерләр белән бергә очраша һәм катлаулы бер бөтен тәшкил итә башлый.

Шагыйрь иҗатының Коръән идеяләре белән якынлыгы аның халкыбыз язмышына ислам фәлсәфәсе, Изге Китап кануннары югарылыгыннан торып бәя бирүеннән килә. Тукай дини мәсьәләләрне милләт язмышыннан аерып карамый. Аныңча, бу бергәлекнең нигезе шәхесне Алла колы дип сукырларча язмышка баш идерүдә түгел, җәмгыятьтәге гаделлек, кешелеклелек, матди һәм рухи тигезлек, зыялы, мәдәни яшәү рәвешендә гәүдәләнә.

Тукай үзенең әсәрләрендә Коръәннән килгән этик фикерләрнең шәхес өчен файдалы, җәмгыять тормышын, кешеләр арасын көйләүдә уңай нәтиҗә бирерлек әһәмиятлеләрен һәрвакыт игътибар үзәгенә куеп, намуслылык, башкаларны рәнҗетмәү, тәкәбберләнмәү, ялганламау, малга табынмау, ата-анага хөрмәт, туганлык кадерен белү, гадел хезмәт белән мал табу, шәфкатьле һәм сабыр булу кебек сыйфатларны олылый. Шагыйрь әсәрләрендәге фикерләр ислам дине кануннары белән каршылыкка керми, Коръәннән килә торган иҗтимагый, әхлакый-этик кануннар белән тирәнтен керешеп, берегеп яши. Коръәндә кат-кат кайтып таләп ителә торган иманлы, игелекле, мәрхәмәтле булу, әхлак, кешелеклелек, гыйлемгә омтылу, тән һәм җан сафлыгы, намуслылык, рухи һәм матди тигезлек кебек төшенчәләр Тукай иҗатының да асылын



тәшкил итә. Ул иҗатының мәгърифәтчелек чорында аеруча гыйлем культын ихластан уртаклаша, шагыйрь фикеренчә, Коръән тәгълиматына, андагы гыйлем турындагы өйрәтмәләргә яңа заман таләбеннән иҗади якын килгәндә, иҗтиһад иткәндә генә татар милләтен алга җибәрергә, иҗтимагый һәм рухани тәрәккыят биеклекләренә күтәрергә мөмкин.

Габдулла Тукай иҗатында һәр нәрсәнең Алланың чиксез кодрәтенә бәйлелектә булуына ышануы нигезендә туган әсәрләр үзенчәлекле бер катлам тәшкил итә. Ул бу мәсьәләгә төрле яклап якын килә. Ләкин күбрәк Алланың бөтен гавам яшәешендә һәм язмышындагы илаһи ролен ачуга игътибар бирә. Мәсәлән, "Тәфсирме? Тәрҗемме?"дә:

Һәр заман кем насры берлән фәтхе килсә Алланың,
Һич тә бер көч туктаталмый, манигы булмый аның

яки "Ана илә бала" шигырендәге "Җиһанда барча эшләр, барча хәлләр Тәңредән, бәгърем" кебек өзекләрдә ул җиһандагы бар үзгәрешләрнең сәбәпчесе Алла икәнлеген күрсәтә.

Тукай иҗатында XX йөз башы Яңарыш мәдәнияте, шул чор татар реалистик һәм романтик әдәбияты өчен гаять актуаль булган хөр шәхес образы тудыру идеаллары, Алла кануннарын хаклау, шәхес хөрлеге мәсьәләләре белән тыгыз үрелеп килә. Тукай Коръән кануннарының үтәлеше җәмгыятьтәге төрле катламнар һәм кешеләр арасындагы әхлакый-иҗтимагый мөнәсәбәтләрне көйләүгә ярдәм итәчәгенә ышаныч белдерә, иҗтимагый-сәяси, социаль мәсьәләләрне чишүдә дә Коръәндә тасвирланган Алла кодрәтенә таяна, табигатьтәге үзгәрешләрне дә, кеше язмышын да Алланың ихтыярына бәйлелектә карый. Тукай беркайчан да татар кешеләренең җир тормышын Илаһияткә бәйләнешле рухи яшәештән аерып куймый. Иң элек бу Алланың барлыгын, Бер булуын тануда, әт-Тәүхид турындагы карашларны бернинди шик-шөбһәсез кабул итүдә күренә. Икенчедән, урта гасыр татар әдәбитының бик күп шагыйрьләречә, Тукай Аллаһы Тәгаләнең аз-Заты турында да сәнгати фикер йөртә, төрки-татар дөньясындагыча Аны төрледән-төрле исемнәр белән атый: Аллам, Тәңре, Ходай, Мәүләм, Серләр ачучы, Илаһ. Өченчедән, Аллаһы Тәгаләнең күп санлы атрибутлары турында сөйләгәндә Аның бөек Кодрәт иясе булуына басым ясый.

Коръәннең төп идеясе булган Алланың барлыгын, берлеген, кодрәтенең чикләнмәгәнлеген, бөек яратучы, иҗатчы икәнлеген тану белән бәйле идеяләр Тукай иҗатында киң чагылыш тапкан.

Мәсәлән, бу фикерләр "Туган авыл" (1909) ("Ходай шунда җан биргән, мин шунда туган…"), "Сөальләр" (1907) ("Йа Ходай! Нигә төрле-төрле кылдың кешеләрне?"), "Өзелгән өмид" (1910) ("Очты дөнья читлегеннән тарсынып күңлем кошы, Шат яратса да, җиһанга ят яраткан Раббысы") шигырьләрендә кешеләрнең Алла тарафыннан яратылуын бәян итү рәвешендә гәүдәләнгән.


Ходайның кодрәтенең чикләнмәгәнлеген кабул итү, аңа ышану Тукай иҗатын күңел нечкәлеге белән сугарылган яңа бер алым - Аллаһтан сорау ялвару, изге теләкдога рәвешендә формалашкан әсәрләр белән баетуга өлеш керткән.

Мондый әсәрләр шагыйрьнең җан авазын укучыга җиткерергә булыша. "Ана догасы", "Тәэссер" (Тукай үзе бу шигырен "Лермонтовның "Молитва" сәрләүхәле шигыренә тәкълид" дип күрсәтә), "Таян Аллага" (1910), "Китап" әсәрләре шундый үзенчәлеккә ия.

Тукайның бөтен яшәү рәвеше, кылган гамәлләре һәм әсәрләрендә алга сөргән фикерләре дә ислам кануннарына нигезләнгән. Коръәндә: "Ий, иман китергәннәр! Сабыр итегез, (дошман каршысында) чыдам булырга тырышыгыз. Нык булыгыз!" ("Әл-Гыймран (Гыймранның

*(Ахыры 4 нче биттә.)*

# МӘҢГЕ СҮНМӘС ӨМЕТ



*(Ахыры. Башы 3 нче биттә.)*

Шушы урында әби авыр итеп көрсенеп куя да, хатирәләр сандыгыннан нәрсәләрдер актарып алып, дәвам итә:

- Ирем сугышта һәлак булып кире әйләнеп кайтмады - бер өметем сүнде. Соңрак улым вафат булды - икенче өметемне җуйдым. И-их, ул юк булган өметләр...

- Әбекәй, ә шул авыр вакытларда, йөрәгеңне әрнетеп өметләр өзелгән чакта нәрсә яшәтте соң сине, нәрсә рухи көч биреп торды?

- Иман яшәү көче бирде, улым, иман... Башкаема төшкән авырлык - ул Раббым биргән сынау икәнлеген аңлау, моңа инанып сабыр итү тормыш авырлыкларын күтәрергә бик тә ярдәм итте миңа. Яшьтән үк тормышымдагы бар өметемне Аллаһка багладым, Раббыбыз вәгъдә иткән ахирәтне истә тотып, һәрбер гамәлемне Аллаһ риза булырлык итеп башкарырга тырыштым, инде кабуллардан гына булсын, йә Рабби...

Карчык чәчәкләре уңа төшкән яулык япкан башын күтәрә һәм тоныкланган күз карашын каядыр читкә һәм бераз өскә юнәлдереп, дерелдәп торган тавыш белән җырлап җибәрә:

"Сабыр итик, сабыр итик,
Сабыр колдан шайтан качар.
Сабыр булган җәннәт ишеген
Үз куллары белән ачар...".

Тынлык. Бары тик стенадагы сәгатьнең текелдәве генә гомер агышының туктамаганлыгын искә төшерә кебек. Ә мин яшь булсам да, аңлыйм: әбинең бүгенге көндә тыныч-тавышсыз калган иске йорты заманында сәгать текелдәвен генә түгел - дәһшәтле гомер давыллары, язмыш гарасатларын да ишеткән, ләкин иман-тәкъвалыгы, гыйбадәте, сабырлыгы Нурания апаны шайтан тәэсиреннән, күңел төшенкелегеннән саклаган, тормышында нык терәк булган.

Кызганыч, динсезлектә тәрбияләнгән, хәрам белән хәләлне аермаган (һәм аерырга теләмәгән) хәзерге җәмгыять кешеләре сынау итеп бирелгән язмыш зилзиләләрен еш кына кичерә алмыйлар. Бу бигрәк тә ир-атларга хас күренеш. Алар гадәттә андый вакытларда эчүгә сабышалар, ягъни авырлыкны шайтан белән бергә "җиңәргә" маташалар, ләкин... шайтан аларны коткарырга түгел, ә киресенчә, хәрамгаияләшкән гөнаһлы хәлләрендә ахирәткә озатырга тырыша башлый һәм Аллаһтан тәмам читләшкән, якты өметен җуйган шул бичара үз-үзенә кул сала. Нәтиҗәдә, бу дөньядан ахирәткә җәһәннәм әһеле булып күчә. Ә шайтанга нәкъ шул кирәк тә инде, чөнки ул үзе - өметсез, ягъни җәннәткә мәңге кермәячәген белә һәм шундый өметсез, бозыклык кылучылар гаскәрен мөмкин кадәр арттыру - аның төп максаты. Шуңа да әбинең мөнәҗәтендә искә алынган сабырлык сыйфаты шушы аяныч, бәхетсез хәлгә дучар булмас өчен бик тә зур әһәмияткә ия. Әлбәттә, әлеге сабырлык Аллаһ ризалыгы өчен булса. Ә Аллаһы Тәгалә авырлыктан соң һичшиксез җиңеллек бирелер дип Үзе вәгъдә итә.

Шулай уйланып, бераз дәшми утырганнан соң, сөйләшүебезне дәвам итәбез.

- Нурания апай, инде гафу ит, ләкин сорыйсым килә: шушы син кичергән хәсрәт-михнәтләр язмышыңнан ризасызлык, Аллаһы Тәгаләгә карата ниндидер үпкәрәнҗү хисләре тудырмадымы?

- И-и, кая инде ул рәнҗүләр, барысы да тәкъдир бит. Бер көнне кояш елмайса, икенче көнне, болытлар куерып, яңгыры коеп үтә, шуның шикелле кеше гомерендә дә сөенече белән көенече алышынып торырга тиештер инде ул. Аллаһы Тәгалә бит һәр кешене сынап карый: шатлык, байлык килгәндә шөкеранә кылырмы, хәсрәт, юклык вакытында сабыр булырмы. Ничек кенә булса да, безне бар кылган Яратучыга тугрылыклы калу - һәр Адәм баласының бурычы, шуңа да мөселман өчен яхшылык та нигъмәт, авырлык та нигъмәт. Әгәр кеше Раббысы белән тиешле мөнәсәбәт булдырса, уйлары пакь, күңеле гел тыныч булыр. "Бәхет нәрсә ул?" дип сорау биргәниең бит, баксаң, бу сорауга җавап кыска гына һәм бик тә гади: күңеле тыныч булган кеше генә чын бәхетле була ала. Ә моның өчен Аллаһы Тәгаләне гел дә истә тотарга, Аның ризалыгын алырга тырышып яшәргә кирәк. Шулай булса гына кеше үзе һәм әйләнә-тирә белән килешер, күңелендә тынгылык урнашыр.

- Димәк, үпкәләмисең, үкенмисең дә?

- Юк, улым, юк... Гыйбадәтемне азрак кылганмын бугай дип кенә үкенсәм инде. Шөкер, Аллаһы Тәгалә миңа озын гомер биргән, тагын күпме яшисе калгандыр, шулай да үземне Раббым хозурына күчәргә әзер кебек хис итәм. Күңелем тыныч минем, улым, Аллаһка шөкер, тыныч...

Шушы мизгелдә, сәер бер дулкынлану хисе кичереп, әбекәйнең күңелендәге тынычлыкка зыян салмыйм диптер инде, мин басынкы тавыш белән, пышылдап диярлек сорыйм:

- Шулай булгач, Нурания апай, син бәхетле?

Әби бермәл уйга калып дәшми утыра, аннары исә әкрен, әмма ныклы, ышанычлы тавыш белән җавап бирә:

- Анысы, балакаем, ахирәттә билгеле булачак. Үлемне каршылау, ахирәткә күчү вакыты һәркемгә дә килеп җитәчәк, барыбер килеп җитә ул көн, килеп җитми калмас. Шуңа да Аллаһның барлыгына-берлегенә ышану, Ул риза булырлык итеп яшәү, Аңа сыену - бик зур нәрсә ул, үскәнем. Моңа инану, моның асылын, хикмәтен аңлау иман була да инде...

## Гыйлем – офык кебек

... Һәрбер кеше бәхеткә омтыла. Әмма һәркем аны үзенчә аңлый. Нурания апа шушы төшенчәнең асылын менә ничек гади дә, тирән мәгънәле итеп тә аңлата белгән бит! Бәхет сере аның өчен фани дөнья максатларына ирешүдә түгел. Һәр нәрсәнең ахыры хәерле булуы һәм нәтиҗәдә Аллаһ ризалыгына ирештерүе мөһим, ди хикмәтле әби. "Раббың белән мөнәсәбәт булдырсаң, уйларың пакь, күңелең исә тыныч булыр..."

Шулай итеп, бәхетле булу өчен Аллаһ риза булырлык итеп яшәү, Аңа сыену, Аның барлыгына-берлегенә ихлас ышану, ягъни Иман кирәк икән бит безгә! Ә хакыйкый иман иясе булу өчен ни кирәк?..

Дөрестән дә, гыйлем ул офык кебек. Аңа якынайган саен, ул синнән ерагая башлый сыман. Әмма шунысы хак: бу дөньяның, барлык тере һәм тере булмаган мәхлукларның, шул исәптән кешенең дә Яратучысы бар. Шушы мәхлукларның һәммәсе дә шул Яратучы билгеләгән кануннарны үти, Адәм балаларына гына, сынау максаты белән ирек бирелгән. Шулай да кешеләр адашып-саташып, нәфес вә шайтанга алданып харап булмасыннар өчен, бөек Раббыбыз Үзенең әмер-тыюларыннан торган "дин" дигән олуг Канун биргән безгә. Кеше булган вакытта дин дә булачак, чөнки дин ул - бәхеткә илтүче бердәнбер дөрес юл, тормышыбызда терәк һәм шатлыклы өмет. Мәңге сүнмәс өмет...

**Ришат хәзрәт КУРАМШИН,**
**Кукмара мәдрәсәсе директоры**

# ИСЛАМ САЙТЛАРЫ АССОЦИАЦИЯСЕ: АЛЛАҺНЫҢ РИЗАЛЫГЫН АЛУ ӨЧЕН КАЛӘМГӘ ТОТЫН!

*(Ахыры. Башы 3 нче биттә.)*

"Петербургта бары тик бер мәчет бар һәм Корбан бәйрәме көннәрендә шул мәчеткә бик күп халык җыела. Әлбәттә, этеш-төртеш булган җирдә төрле хәлләр килеп чыга. Тик шуны кесә телефонына төшереп, интернетка кую дин әһелләренең уңай образын булдырыйм дип тырышып йөрүче мөселман гаммәви матбугат чараларының бар тырышлыгын бер селтәнүдә юкка чыгара.

Д.Гәрәев мөселманнарны күбрәк дөньяви мәгълүмат чаралары эшендә катнашырга чакырды, чөнки алар бүгенге көндә җәмгыятебездә зур урын алып тора.

**"МАТБУГАТ ЧАРАЛАРЫНЫҢ БЕРДӘНБЕР БУРЫЧЫ"**

"IslamNews" мәгълүмат агентлыгы вәкиле Назыйм Гаффаров фикеренчә, матбугат чараларының бердәнбер бурычы - "үзенең укучысы белән гел янәшәдә булу, аның ихтыяҗын канәгатьләндерү һәм аңа турылыклы хезмәт итү".

***Алсу БАДАЕВА,***
***"Islam today" мәгълүмати-аналитик федераль порталы***

# Габдулла Тукай иҗаты һәм илаһият кануннары

*(Ахыры. Башы 3 нче биттә.)*

гаиләсе)" сүрәсенең 200 нче аяте), - дип әйтелсә, хәдистә исә: "Аллаһы Тәгалә каршында олы көрәшнең берсе - явыз җитәкче каршында булсаң да, дөресен әйтү", - диелә. Шагыйрьнең "Бер татар шагыйренең сүзләре" нәкъ шул фикерләрне раслый. Шагыйрь "дошманнар көченнән шикләнми", "хәсрәт-кайгыга каршы тора", "яхшылыкны мактый, яманлыкны сүгә", "юлдагы киртәләрне тибеп аудара", "дусларына дустанә мөгамәлә саклый". Бу шагыйрьнең (шул исәптән Тукайның үзенең дә) яшәү кануннары, иҗат шигаре булып яңгырый. Ул тормышының бөтен мәгънәсен Аллага һәм халкына хезмәт итүдә күрә:

Тиеш имеш үтәргә изге юлда бу гомер барсы
Түләү берлә бурычны Тәңремә һәм халкыма каршы.
Бәхетлемен шушы хәлдән, бүтән бер хәл көтмимен,
Шушы юлдан ризамын, башка төрле бер юл да тотмыймын.
Артка бакма, даһием, идеал һаман да алда ул;
Алга барганнарга тик табыла табылса - Алла ул! -

дигән шигырь юлларының да асылы шул мәгънәгә хезмәт итә.

Шагыйрь күңеле кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрнең ялганга корылуын, капиталистик җәмгыятьтә бар нәрсәнең акча, мал белән бәяләнеп, рухи кыйммәтләрнең икенче планга кайтарылуын авыр кичерә. Мондый тормыш аңа мәгънәсез тоела. "Гомер хакында" шигырендә:

Бик күңелсез бер начар журнал - гомер,
Анда, әлбәт, баш мәкалә мал ирер, - ди.

"Сорыкортларга" (1906), "Матбага берлә уйнаган бер байга" (1907), "Тотса мәскәүләр якаң" (1908), "Тәләһһеф" (1910) кебек шигырьләрендә, "Алай-болай" (1906), "Уральск имамнарына ачык хат" (1906) кебек мәкаләләрендә намусын, иманын һәм диненен тамак ялына, тиеннәргә саткан бәндәләрне гыйбрәтле тәнкыйть утына тота.

Ул кешенең шәхси әхлагы өлкәсендә дә ислам кануннары белән каршылыкка кергән эш-гамәлләргә каршы чыга. Әйтик, "Читен хәл" (1911), "Катиле нәфескә" (1910) әсәрләрендә үз-үзеңә кул салу, ә "Кечкенә бер көйле хикәя" (1906), "Авыл җырлары" (1911) шигырьләрендә, "Тиешсез эш" игъланында зина кылу кебек хәрам гамәлләр кире кагыла.

Үзеңнән көчсезләргә, мохтаҗларга ярдәм кулы сузу, яхшылык эшләү, ялганнан, ялкаулыктан читтә булу, тырышлык кебек сыйфатлар балалар өчен язылган әсәрләрендә дә аерым урын били. "Бәхетле бала" (1909), "Күгәрчен" (1910), "Фатима белән Сандугач" (1910) һәм башка бик күп кенә әсәрләре шуңа мисал.

Тукай яшәү дәверендә илаһият кануннарын саклап, аларга хөрмәт тотып яши. Кешелекнең асылын саклауда, җәмгыятьне төрле авырулардан, кимчелекләрдән чистартуда да, үзара мөнәсәбәтләр сафлыгында да аңа таяна. Бер гасырдан соң да аның әсәрләренең халкыбыз тарафыннан сөеп укылуының сәбәбе дә шунда.

**Диләрия АБДУЛЛИНА,**
**филология фәннәре кандидаты,**
**Г.Ибраһимов ис. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының әйдәп баручы фәнни хезмәткәре**

**«Дин вә мәгыйшәт» газетасы. № 26 (169) чыгарылыш.**
**Гамәлгә куючы һәм нәшир:** Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте.
**Баш мөхәррир:** Ришат ХӘМИДУЛЛИН.
**Мөхәррир:** Нияз САБИРҖАНОВ.
**Дизайнер:** Рөстәм МИҢНУЛЛИН.
**Тираж:** 5000 данә. **Заказ:** 9431.

**Газетаны ваклап сатуда тәкъдим ителгән бәя - 3,00 сум.**
**Редакция адресы:** 420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27.
***График буенча бу санга 27 декабрь көнне 17.00 сәгатьтә кул куелырга тиеш иде. Кул куелды – 17.00 сәгатьтә.***
*Теркәлү турында таныклык: Татарстан матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 елның 16 февралендә 240 нчы номер белән теркәлде.*
**Электрон адрес:** niyaz.kazan@yandex.ru **Тел.:** 8(843)267-29-67.

Газета "Татмедиа" ААҖ филиалы – "Идел-Пресс" полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты (420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2).

**Газетада Аллаһы Тәгаләнең исемнәре, Коръәннән аятьләр бар, тиешсез урынга кулланудан сакланыгыз!**